Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Кузайкино авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

26 ноябрь 2019 ел N 10

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Кузайкино авыл җирлегенең
Кузайкино авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 07 декабрь, 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлегенең Кузайкино авылында Жданова, Заречная, Набережная, Полевая урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2019 елның 07 декабрь, 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлегенең Кузайкино авылында Совет урамында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2019 елның 07 декабрь, 16 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлегенең Кузайкино авылында Хрусталева, Школьная урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кузайкино авыл җирлегенең Кузайкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: «Сез Кузайкино авыл җирлеге территориясендә 2020 елда яшәү урыны җирлек территориясендә булган һәр балигъ яшьтәге гражданинның вак таштан салынган юлларны норматив хәлгә китерү өчен бер тапкыр 400 (дүрт йөз) сум акча түләвен кертергә ризамы?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Халык җыены этапларын Кузайкино авыл мәдәният йорты бинасында, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы Әлмәт районы, Кузайкино авылы, Совет урамы, 26 йортта уздырырга.

6. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлегенең Кузайкино авылында сайлау хокукына ия булган авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

7. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Кузайкино авылы, Совет урамы, 26 нче йорт территориясендә урнашкан махсус

мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

9. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Кузайкино
авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Шәйхетдинов